Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Советы

**КАРАР №6**

Югары Ырга авылы 08 август 2024

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 нче сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Югары Ырга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (04.09.2017 ел №12; 15.11.2018 ел №15; 03.09.2019 ел №13, 02.11.2020 №5 карарлар ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) түбәндәге эчтәлектәге 4.6.1.9 - 4.6.1.12 пунктчаларны өстәргә:

«4.6.1.9. Контейнер капкачы ябылганчы булган күләменә кадәр генә тутырылырга тиеш (контейнерның өске кырыеннан югары түгел). Контейнердагы калдыкларны мусоровозга бушатканда, аларны коеп, төшереп булмаслык итеп, тутыру барышында пресслау яки тыгызлап төю һәм куелган күләмнән артык контейнерны тутыру тыела.

4.6.1.10. Каты коммуналь калдыклар өчен контейнерларга эре габаритлы калдыклар, автомобиль шиннары һәм покрышкалар, сыек матдәләр, авыл хуҗалыгы калдыклары, биологик калдыклар, биологик һәм химик актив калдыклар, терекөмеше булган яктырту приборлары һәм электр лампалары, ток (батарея һәм аккумуляторлар) химик чыганаклары, медицина калдыклары, үсемлек калдыклары, җир кишәрлекләрендә эшләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән калдыклар, төзелеш калдыклары урнаштыру тыела.

4.6.1.11. Каты коммуналь калдыкларны һәм эре габаритлы калдыкларны, шулай ук 4.6.1.10 пунктында күрсәтелгән калдыкларны контейнерлардан һәм бункерлардан тыш урнаштыру (ташлау, ыргыту) тыела.

4.6.1.12. Төзелеш чүп-чарларын һәм контейнерларга яки бункерларга урнаштыру тыелган башка төр чүп-чарны чыгару калдыкларның хуҗалары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә яисә коммуналь хезмәтләргә үз хисабыннан полигоннарга заявка бирү юлы белән башкарыла (калдыкларны урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган корылмалар).»;

1.2) 4.6.1.9-4.6.1.14 пунктчаларын тиңдәшле рәвештә 4.6.1.13-4.6.1.18 пунктчалары дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Югары Ырга авылы, М.Җәлил урамы, 18 йорт, Яңа Ырга авылы, Мәктәп урамы 48 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Югары Ырга авыл җирлеге Башлыгы Р.Н.Багаутдинов